ГЛАВА КАНАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Центральная, д.28, д. им. М. Вахитова,
422575

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КАНАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Үзәк ур., 28 нче йорт, М. Вахитов исем авылы,
422575

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

03.10.2023 д. Канаш № 7

Гражданнарның үзара салымын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлеге Йолдыз авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче статьясына, Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлеге Уставынаың 24 ст. туры китереп,

КАРАР БИРӘМ:

1.2023 елның 20 октябренә Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлеге Йолдыз авылында гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлеге Йолдыз авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2024 елда 3000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүбелән килешәсезме:

«Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлеге Йолдыз авылына керү юлындагы күперне реконструкцияләү»

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын: Йолдыз авылы, Урман урамы адресы буенча, 11 йорт янында 10.00 сәгатьтә үткәрергә.

4. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Канаш авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Канаш авыл җирлеге башлыгы Н.Н.Вальков